ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.12.2020 Казан ш. № 543-8-т-2020

«Юл хәрәкәте иминлеге» ДБУ өчен Татарстан Республикасында тоткарланган транспорт чараларын махсуслаштырылган стоянкаларга күчерүгә 2021-2025 елларга тарифлар билгеләү хакында

Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе Кодексының 27.13 статьясы, Монополиягә каршы федераль хезмәтнең «Тоткарланган транспорт чараларын күчерүгә һәм саклауга тарифларны исәпләү һәм түләү срокларын билгеләү буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2016 елның 15 августындагы 1145/16 номерлы боерыгы, «Тоткарланган транспорт чараларын махсуслаштырылган стоянкага күчерү, аларны саклау, кире кайтару, күчерү һәм саклау хакын түләү тәртибе турында» 2012 елның 17 маендагы 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге карар кушымтасына туры китереп, «Юл хәрәкәте иминлеге» ДБУ өчен 2021 елның 1 гыйнварыннан 2025 елның 31 декабренә кадәр Татарстан Республикасында тоткарланган транспорт чараларын махсус стоянкаларга күчерүгә тарифлар билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасында тоткарланган транспорт чараларын махсуслаштырылган стоянкаларда күчерүгә һәм саклауга тарифлар билгеләү турында» 07.09.2018 № 7-8/т карары гамәлдән чыккан дип танырга.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы А.Л. Штром

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
17.12.2020 № 543-8-т-2020
карарына кушымта

«Юл хәрәкәте иминлеге» ДБУ өчен Татарстан Республикасында тоткарланган транспорт чараларын махсуслаштырылган стоянкаларга күчерүгә 2021-2025 елларга тарифлар

| № | Эшләр һәм хезмәтләр аталышы | Дәүләт комитеты исәпләмәсе | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел |
| 1. | Тоткарланган транспорт чарасын махсус машина кую урынына күчерү, бер транспорт чарасын күчергән өчен | 2940,90 | 3067,36 | 3199,25 | 3333,6 | 3473,63 |
| | шул исәптән: | | | | | |
| 1.1. | төяү-бушату эшләре | 850,64 | 887,218 | 925,368 | 964,23 | 1004,73 |

Искәрмә:

Төяү-бушату эшләре өчен түләү транспорт чарасын тоткарлау сәбәпләре юкка чыгарылганнан соң аны махсус транспорт чарасына төягәч һәм махсус машина кую урынына саклау өчен урнаштырганчыга кадәр алына.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф чишелешләрен
кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм
теркәү бүлеге